РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«25» июль, 2016 ел Олы Кайбыч ав. №46

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык хакында нигезләмәне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» 2011 елның 01 августындагы 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турындагы нигезләмәне расларга.

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда игълан итәргә (бастырып чыгарырга) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Совет Рәисе-**
**Кайбыч муниципаль районы Башлыгы** **А.И.Рәхмәтуллин**

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Советының
2016 елның "25" июль
46 номерлы карарына кушымта

# Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль - хосусый партнерлык турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турындагы нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында (алга таба текст буенча-муниципаль район ) муниципаль берәмлек исеменнән килешүләр төзү һәм үтәү юлы белән муниципаль-хосусый партнерлыкта катнашу тәртибен һәм шартларын билгели.

1.2. Муниципаль-хосусый партнерлыкның максатлары түбәндәгеләр:

1) Кайбыч муниципаль районы территориясендә аның социаль-икътисадый үсешенә юнәлтелгән иҗтимагый әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыру;

2) шәхси инвестицияләр җәлеп итү;

3) муниципаль милектәге мөлкәттән (алга таба - муниципаль мөлкәт) файдалануның нәтиҗәлелеген тәэмин итү, шулай ук муниципаль районның җирле әһәмияттәге башка мәсьәләләрен хәл итү;

4) җирле продукциянең конкурентлык сәләтен, шулай ук куллнучыларга күрсәтелә торган товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең сыйфатын арттыру;

5) яңа эш урыннары булдыру.

1.3. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) муниципаль-хосусый партнерлык - муниципаль районның әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән шәхси эшкуарлар һәм юридик затлар белән үзара файдалы хезмәттәшлеге, ул Кайбыч муниципаль районы территориясендә социаль әһәмияткә ия, инвестиция, инфраструктура, инновацион проектларны һәм программаларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән килешүләр төзү һәм үтәү юлы белән гамәлгә ашырыла;

2) муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү - Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башкарма комитеты һәм юридик зат, индивидуаль эшкуар йөзендә әлеге Нигезләмәдә һәм муниципаль районның норматив хокукый актларында каралган рәвешләрдә муниципаль-хосусый партнерлык нигезендә эшчәнлекне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге арасында төзелә торган шартнамә (алга таба - килешү);

3) муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү объекты - реконструкцияләнә, модернизацияләнә, рекультивацияләнә, хезмәт күрсәтә, файдаланыла торган муниципаль мөлкәт килешүе нигезендә төзелә;

4) конкурс - әлеге Нигезләмә нигезендә, шулай ук Россия Федерациясенең

гамәлдәге законнары таләпләре нигезендә башкарыла торган килешүне төзү хокукына, торглар шартлары килешү торгларын җиңүче белән килешү, җир кишәрлеген, башка күчемсез һәм (яисә) күчемле муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәсен төзүне күздә тоткан очракта.

1.4. Муниципаль-хосусый партнерлык түбәндәге принципларга нигезләнә:

1) законлылык;

2) муниципаль-хосусый партнерлык якларының үзара файдалы хезмәттәшлеге;

3) муниципаль-хосусый партнерлык якларының үзара мөнәсәбәтләренең шартнамәчел нигезе;

4) муниципаль һәм хосусый мәнфәгатьләрнең нисбәтлелеге;

5) муниципаль-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашырганда җирле бюджет акчаларыннан файдалануның максималь нәтиҗәлелеге;

6) муниципаль-хосусый партнерлык һәм аларны иминләштерү яклары арасында җаваплылыкны һәм куркынычларны аеру;

7) финанс, матди, оештыру ресурслары кооперацияләре;

8) муниципаль-хосусый партнерлык проектларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге;

9) муниципаль-хосусый партнерлыкның барлык якларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү;

10) муниципаль-хосусый партнерлык яклары мөнәсәбәтләренең хәбәрдарлыгы һәм ачыклыгы.

## 2. Муниципаль районның муниципаль-хосусый партнерлыкта катнашуы

2.1. Муниципаль районның муниципаль-хосусый партнерлыкта катнашуы түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

1) «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә концессион килешүләр төзү;

2) капиталь кертемнәр рәвешендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция эшчәнлегендә «Россия Федерациясендә капитал салулар рәвешендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция эшчәнлеге турында» 1999 елның 25 февралендәге 39-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган тәртиптә катнашу;

3) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә төзелгән территорияне үстерү турында шартнамәләр төзү;

4) муниципаль-хосусый партнерлык турында һәм хосусый партнерга килешү объектын төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү, рекультивацияләү һәм хосусый партнерның килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм шартнамәдә билгеләнгән шартларда аннан соң файдалануын гамәлгә ашыру максатларында муниципаль-хосусый партнерлык турында килешүләр төзү һәм муниципаль мөлкәтне хосусый партнерга бирү максатларында килешү тәмамланганнан соң аны муниципаль районына тапшыра торган вакыт эчендә яисә килешү объектыннан файдаланып төзелгән килешү, товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтелгән тәртиптә һәм шартларда хосусый партнер тарафыннан күрсәтелә;

5) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль норматив хокукый актларга каршы килми торган башка рәвешләрдән файдалану.

Әлеге пунктта күрсәтелгән катнашу рәвешләрен исәпкә алып, муниципаль районның муниципаль-хосусый партнерлыкта катнашуы Россия Федерациясенең

гамәлдәге законнары һәм әлеге Нигезләмә таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.2. Килешүләр төзегән хосусый партнерларга бирелә торган җир кишәрлекләре һәм башка муниципаль мөлкәт өчен җирле салымнар һәм аренда түләве буенча ташламалар билгеләү Россия Федерациясе законнары һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.3. Муниципаль районның район бюджеты акчаларын тотуны күздә тоткан муниципаль-хосусый партнерлыкта катнашуы бюджет ассигнованиеләрен әлеге максатларга чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турындагы карарга керткәндә мөмкин.

**3. Муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү объектлары**

3.1. Муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү объектлары түбәндәгеләр:

1) транспорт һәм юл инфраструктурасы;

2) коммуналь инфраструктура объектлары;

3) җылылык энергиясен җитештерү, тапшыру һәм бүлү объектлары;

4) мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, спорт, туризм, рекреация һәм социаль хезмәт күрсәтү объектлары, социаль-мәдәни билгеләнештәге башка объектлар;

5) сәүдә, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм җәмәгать туклануы объектлары;

6) муниципаль район территориясендә урнашкан күчемсез мөлкәтнең башка объектлары.

3.2. Килешү объектын төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү, рекультивацияләү, файдалану һәм эксплуатацияләү, әгәр Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары белән башкасы билгеләнмәгән булса, килешү һәм аренда шартнамәсе шартларында рөхсәт ителә.

**4. Муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендә муниципаль районның җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

4.1. Муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендә муниципаль район Советы:

- муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актлар кабул итә,

- муниципаль район бюджеты составында муниципаль-хосусый партнерлыкта муниципаль район катнашуына бәйле чыгымнарны раслый,

- ел саен муниципаль районның башкарма комитеты тәкъдим иткән килешүләр турындагы мәгълүматны карый,

- муниципаль-хосусый партнерлык мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль район Советы карарларының үтәлешен һәм башкарылуын тикшереп тора,

- федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль районның норматив хокукый актлары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

4.2. Муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендә муниципаль район башкарма комитеты:

- муниципаль-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актлар кабул итә;

- муниципаль милектәге мөлкәттән муниципаль-хосусый партнерлык максатларында файдалану турында карарлар кабул итә;

- муниципаль-хосусый партнерлыктан файдаланып, муниципаль максатчан программалар кабул итә;

- килешүләр һәм аренда шартнамәләре төзү хокукына конкурслар оештыра һәм үткәрә;

- муниципаль-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашыру турында муниципаль район советына ел саен мәгълүмат бирә;

- килешү төзү турында тәкъдимнәр әзерли йә килешү төзү турында хосусый партнер тәкъдимнәрен карый һәм аның буенча карар кабул итә;

- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль районның муниципаль хокукый актлары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

4.3.Муниципаль район Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге килешүләр реестрын алып бара, төзелгән килешү кысаларында квартал саен килешү үтәлешен мониторинглый.

## 5. Муниципаль-хосусый партнерлыкта муниципаль районның катнашуы турында карар кабул итү нигезләре

Муниципаль районның муниципаль-хосусый партнерлыкта катнашуы турында карар кабул итү нигезләре түбәндәгеләр:

- муниципаль районның социаль-икътисадый үсеш программасында билгеләнгән максатларга һәм бурычларга, шулай ук алар нигезендә эшләнә торган муниципаль программаларга туры килүе;

- финанслауның бюджеттан тыш чыганакларын җәлеп итү зарурлыгы;

- муниципаль район халкына күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын һәм күләмен арттыру;

- социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен күтәрү зарурлыгы;

- муниципаль район милкендәге мөлкәт белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү.

## 6. Муниципаль-хосусый партнерлык турында тәкъдимнәрне карау тәртибе

6.1. Юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән муниципаль-хосусый партнерлык турындагы тәкъдимнәрдә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

- муниципаль-хосусый партнерлык объекты;

- муниципаль-хосусый партнерлыкны (бизнес-план) гамәлгә ашыруның техник-икътисадый күрсәткечләре;

- муниципаль-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашыру сроклары;

- хосусый партнер тарафыннан бирелә торган гарантияләр;

- муниципаль район бюджетыннан финанслау күләмнәре, муниципаль-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашыру өчен җәлеп ителергә тиешле муниципаль мөлкәт исемлеге;

- муниципаль-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашыру өчен җәлеп ителергә тиешле акчалар һәм хосусый партнерның мөлкәте күләме.

6.2. Муниципаль-хосусый партнерлык турындагы тәкъдим (проектны гамәлгә ашыру турындагы тәкъдим) район башлыгы исеменә җибәрелә һәм алга таба муниципаль районның башкарма комитетына юллана.

Муниципаль район башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге финанс-бюджет палатасы, милек һәм җир мөнәсәбәтләре палаталары җитәкчеләренә бәяләмәләр әзерләү өчен тәкъдимнәр җибәрә. Бәяләмәдә килешү шартларының тәкъдим ителә торган вариантлары тәкъдимнең максатка ярашлылыгын нигезләү булырга тиеш. Муниципаль район Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү төзүнең максатчанлыгын икътисадый нигезләүне әзерли һәм аны муниципаль районның Инвестицион советы каравына чыгара.

6.3. Федераль законнарда каралган очракларда муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү торглар (конкурс) уздыру нәтиҗәләре буенча төзелә.

## 7. Муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү

7.1. Муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешү гамәлдәге законнар нигезендә язма рәвештә төзелә һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) килешү объекты;

2) муниципаль районның муниципаль-хосусый партнерлыкта катнашу рәвеше;

3) килешүнең гамәлдә булу срогы яисә аны билгеләү тәртибе;

4) килешү яклары арасында куркынычларны бүлү;

5) килешү якларының хокуклары һәм бурычлары;

6) килешү яклары арасында исәп-хисаплар тәртибе;

7) хосусый партнер белән килешү буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү ысуллары, бирелә торган тәэмин итү күләмнәре һәм ул бирелә торган вакыт;

8) килешү объектының хосусый партнеры тарафыннан төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү, рекультивацияләү, эксплуатацияләү, хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары;

9) килешү якларының аны төзегәндә һәм үтәгәндә хокуклары гарантияләре;

10) килешү шартларын берьяклы үзгәртү һәм (яисә) аны өзү очраклары булу;

11) килешүгә үзгәрешләр кертү һәм килешүнең гамәлдә булуын туктату тәртибе;

12) бәхәсләрне хәл итү тәртибе;

13) килешүне үтәмәгән һәм (яисә) килешү буенча йөкләмәләрне тиешенчә үтәмәгән өчен якларның җаваплылыгы;

14) килешү шартларының үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе.

7.2. Килешү гамәлдәге федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм муниципаль норматив хокукый актларга каршы килмәгән башка шартларны күздә тота ала.